РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

20.11.2023 — № 1810-п

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 апрелендәге 617-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары яшь белгечләренә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр билгеләү турында" 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2022 елның 18 ноябрендәге 1234 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмалары яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 апрелендәге 617-п номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**1.1.** 1 пунктның икенче абзацында «1 111» саннарын «2 510» саннарына алмаштырырга;

**2.** "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләренә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр билгеләү турында" Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 апрелендәге 617-п номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында спорт резервын әзерләүче, муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә - хезмәткәрләргә, аларга карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Саба муниципаль районы Башкарма комитеты башкара, акчалата түләүләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.1.** 1 пунктның икенче абзацында «1 111» саннарын «2 510» саннарына алмаштырырга;

**2.2.** 9 пунктның бишенче абзацында «1 111» саннарын «2 510» саннарына алмаштырырга.

**3.** Әлеге карарның гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

**4.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазифаларын башкаручы,
җитәкче урынбасары –
Саба муниципаль районы
Башкарма комитет аппараты
җитәкчесе М.Р. Кәримов